КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 октябрь г.Казань № 835

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 октябрь, 1207 нче; 2024 ел, 29 июнь, 480 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау дәрәҗәсен, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 октябрь, 835 нче
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

## I. Социаль-икътисадый үсеш һәм милли иминлек өлкәсендәге агымдагы торышны бәяләү

«Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) ггражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау дәрәҗәсен, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген арттыруга, гражданнар оборонасы бурычларын үтәүгә, кешеләрне, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне коткаруга һәм гадәттән тыш хәлләр аркасында зыян күргән халыкка ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелде.

Хәзерге шартларда техноген, табигый һәм террорчылык характерындагы тискәре факторлар Татарстан Республикасының тотрыклы һәм имин үсеше һәм халыкның тормыш сыйфатын яхшырту өчен иң реаль куркынычларның берсе булып тора. Климатның глобаль үзгәрүе, хуҗалык эшчәнлеге процессында яисә зур техноген аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә барлыкка килә торган табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләр куркынычы Татарстан Республикасы халкы һәм икътисад объектлары өчен сизелерлек куркыныч тудыра.

Россия Федерациясе халкын һәм территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы турындагы дәүләт докладлары нигезендә ел саен төбәкләрнең тотрыклы социаль-икътисадый үсешенә куркыныч тудыра торган куркыныч табигать күренешләре һәм зур техноген аварияләр һәм катастрофалар саны арта.

Әйләнә-тирә мохит үзгәрүенең тискәре тенденциясе саклана, ул уңайсыз һәм куркыныч табигый күренешләрнең һәм процессларның активлашуында һәм, димәк,

табигый бәла-казаларның ешлыгы һәм масштаблары артуда, табигый бәла-казаларның техноген катастрофаларга үсүендә һәм киресенчә чагыла.

Кеше факторы техноген аварияләрнең һәм янгыннарның төп сәбәпләренең берсе булып кала бирә. Транспорт, энергетика, торак-коммуналь хуҗалык кебек икътисадның мөһим тармакларында аварияләрнең югары дәрәҗәсе саклана. Янгыннардан турыдан-туры зыян масштаблары төбәк икътисады өчен алар салган зыяннарның авыр булуын күрсәтә.

Су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә килгәндә исә, пляжларны һәм халык күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү өлкәсендә җитди проблемалар, халык белән пропаганда-профилактика эшендә җитешсезлекләр тудыра.

Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында, гадәттән тыш хәлләрдә халыкны һәм территорияләрне саклау өлкәсендә бурычларны хәл итү өчен махсус вәкаләтле, даими эшләүче гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары белән берлектә, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы төзелде. Система Татарстан Республикасының Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләреннән, янгыннан ирекле саклау, ведомство янгынга каршы хезмәте, муниципаль янгыннан саклау, һәлакәттән коткару һәм эзләү-коткару формированиеләреннән, гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрдән тора. Гражданнар оборонасы идарәсе органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре Татарстан Республикасы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук гадәттән тыш хәлләр вакытында килеп чыга торган куркынычлардан саклауга әзерләнү һәм сакклау бурычларын үти.

Килеп чыга һәм фаразлана торган гадәттән тыш хәлләр, хәрби хәрәкәтләр алып баруның яңа формаларын һәм ысулларын куллану Гражданнар оборонасы көчләренең матди-техник базасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү буенча яңа бурычларны хәл итү өчен кирәкле матди-техник тәэмин итү дәрәҗәсеннән сан һәм сыйфат ягыннан артта калуга алшартлар тудыра.

Халыкны янгыннардан, гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм суда иминлекне тәэмин итү өлкәсендә әлеге проблемаларны хәл итү өстенлекле чараларны билгеләгәндә комплексилы якын килүне, аларны гамәлгә ашыруда эзлеклелекне һәм бу процесска хакимиятнең барлык дәрәҗәләрен, предприятиеләрне һәм оешмаларны җәлеп итүне, Татарстан Республикасы халкының үз-үзен куркынычсыз тоту культурасын формалаштыру буенча системалы эшне таләп итә.

2014 – 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итте:

янгыннар саны 4 217 гә кадәр кимеде (2024 елда янгыннар саны 4 992 очрак тәшкил итте);

янгыннарда һәлак булучылар саны 115 кешегә кадәр кимеде (2024 елда янгыннарда һәлак булучылар саны 126 кеше тәшкил итте);

янгыннарда зыян күрүчеләр саны 202 кешегә кадәр кимеде (2024 елда янгыннарда җәрәхәтләнүчеләр саны 205 кеше тәшкил итте);

су объектларында һәлакәтләр саны 100 кешегә кадәр кимеде (2024 елда суда һәлакәтләр саны 114 очрак тәшкил итте);

су объектларында һәлак булучылар саны 82 кешегә кадәр кимеде (2024 елда суда һәлак булучылар саны 86 кешегә җитте);

су объектларында коткарылучылар саны (судагы һәлакәтләр саны кимүгә пропорциональ рәвештә) 38 кешегә кадәр кимеде (2024 елда суда коткарылучылар саны 105 кеше тәшкил итте);

беренче янгын сүндерү бүлекчәләренең чакыру урынына уртача килү вакыты арттырылмады (шәһәрдә – 7,9 минут һәм авыл җирендә – 16,3 минут);

гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен квалификация күтәрү курсларында өзлексез әзерләү системасы оештырылды (2024 елда квалификация күтәрү курсларында белем алган кешеләр саны 8 612 кеше тәшкил итте);

«112» бердәм номеры буенча кабул ителгән, эшкәртелгән һәм ашыгыч оператив хезмәтләргә җибәрелгән чакырулар саны бермә-бер артты (2022 елда кабул ителгән һәм эшкәртелгән чакырулар саны – 20 миллион чамасы, 2024 елда 22 миллион чамасы тәшкил итте);

гражданнарның медик-социаль һәм психологик тернәкләндерү буенча түләүсез хезмәт күрсәтү хокукын гамәлгә ашыру (28 700 койка-көн) һәм «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Ш.С.Каратай исемендәге Республика реабилитация үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә пациентларны реабилитацияләү нәтиҗәлелеге (98,8 процент) 100 процентка тәэмин ителде;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) көчләренең һәм чараларының билгеләнгән гамәлләргә 100 процент әзерлеге тәэмин ителде.

Моннан тыш, 2024 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов тарафыннан расланган хәбәр итү системасын тикшерү актлары нигезендә Халыкка хәбәр итү системаларына эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне оештыру буенча нигезләмә таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы халкына хәбәр итә торган төбәк системасының техник торышы «канәгатьләнерлек түгел» дип бәяләнде. Татарстан Республикасы халкына хәбәр итә торган яңа төбәк системасын булдыру турында карар кабул ителде, йөкләмәләр исемлеге расланды, проектны башкаручылар билгеләнде. Программа чарасын финанслау Татарстан Республикасы бюджетының «Татарстан Республикасы халкына хәбәр итә торган төбәк системасын карап тору һәм эшләтү чаралары башкарылды» дигән максатчан статьясында

каралган акча исәбеннән 2027 елга кадәр планлаштырылды.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга каралган финанс чараларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру өчен чаралар эчтәлегенә һәм күрсәткечләрне актуальләштерүгә үз вакытында тиешле төзәтмәләр кертелә, социаль-икътисадый үсеш һәм иминлекне тәэмин итү өлкәсендә үзгәреп тора торган шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инструментлар җыелмасы камилләштерелә.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

Татарстан Республикасы халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәте максатларына ирешүгә ярдәм итә, чөнки Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясындагы 1 өлешенең «з» пункты нигезендә һәлакәтләргә, табигый бәла-казаларга, эпидемияләргә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру, алар салган зыяннарны бетерү Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында тора.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган чаралар, кеше капиталын булдыру һәм туплау кебек стратегик өстенлектән чыгып, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе (алга таба – Стратегия-2030) максатларына ирешүгә ярдәм итә.

Гражданнар оборонасын үстерү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү максаты – табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән, янгыннардан һәм су объектларындагы һәлакәтләрдән халыкка, икътисадка һәм табигый мохиткә китерелә торган социаль, икътисадый һәм экологик зыянны минимальләштерү.

Гражданнар оборонасын үстерү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең имилеген тәэмин итү өлкәсендә өстенлекле юнәлешләр:

гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм стратегик планлаштыру системасын үстерү;

хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрдән халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау ысулларын һәм алымнарын камилләштерү;

халыкка хәбәр итү системаларын даими әзерлектә тоту;

гражданнар оборонасы белән идарә итү системасын, шулай ук хәрби

конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системаларын камилләштерү;

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасы эшләвен, үсешен һәм аны камилләштерүне тәэмин итү, иҗтимагый иминлекне тәэмин итү, халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү комплекслы системасына интеграцияләү;

халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү һәм хәвеф-хәтәр килеп чыгу куркынычы турында халыкка үз вакытында хәбәр итү өчен инновацион технологияләр кертү, шулай ук янгыннарда кешеләрне коткару чараларын һәм янгыннарны сүндерү чараларын куллану;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен билгеләнгән финанс һәм матди ресурслар резервларын куллануга әзерлекне тәэмин итү;

янгыннарны профилактикалау, аларны сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкару максатларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасын үстерү;

ирекле янгын сүндерү хезмәтен үстерү;

янгыннан саклау бүлекчәләренең, эзләү-коткару хезмәтенең, һәлакәттән коткару формированиеләренең матди-техник базасын һәм әзерлек системасын үстерү;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын, су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген камилләштерү.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлары һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт программасының максаты һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең илкүләм иминлеге стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясен үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы һәм 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм план белән расланган илкүләм мәнфәгатьләреннән һәм стратегик өстенлекләрдән чыгып билгеләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру турыдан-туры түбәндәгеләргә юнәлдереләчәк:

«халыкны саклап калу, кешеләрнең сәламәтлеге һәм иминлеге» илкүләм үсеш максатына ирешүгә;

«Дәүләт һәм җәмәгать иминлеге» стратегик илкүләм өстенлегенә ирешүгә:

янгыннар, су объектларындагы һәлакәтләр санын һәм аларда һәлак булган халык санын киметүгә;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чаралары нәтиҗәлелеген арттыруга;

хәл ителә торган бурычлары нигезендә хокук саклау органнарын, махсус хезмәтләрне, янгыннан саклау бүлекчәләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен комплекслы үстерү, аларның техник тәэмин ителеше дәрәҗәсен арттыру, аларның хезмәткәрләренең социаль яклангалыгын көчәйтү, дәүләт иминлеген һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү өлкәсендә белгечләрне һөнәри әзерләү системасын камилләштерүгә;

«Ил оборонасы» стратегик илкүләм өстенлегенә ирешүгә:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның тыныч вакыттагы шәхси состав белән тулысынча комплектланган булуга (исемлектәге шәхси состав санының тыныч вакыттагы штат санына нисбәте);

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм тыныч (хәрби) вакыттагы органнарның корал, хәрби һәм махсус техника төрләре (тыныч (хәрби) вакыттагы штат-табель ихтыяҗына карата корал, хәрби һәм махсус техника төрләре булу нисбәте), шул исәптән төзек техника төрләре (тыныч (хәрби) вакыттагы штат-табель ихтыяҗына карата корал, хәрби һәм махсус техниканың төзек төрләре булу нисбәте) белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе;

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның матди чаралар төрләре буенча запасы белән тәэмин ителеше (хәрби запаслар, оператив запаслар һәм үзәк запаслары; билгеләнгән нормаларга карата тупланган запаслар булу нисбәте);

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби вакыттагы штатлар буенча мобилизация кешеләр һәм транспорт ресурслары белән тулысынча комплектланган булуы һәм аның сыйфаты;

хәрби конфликтлар һәм гадәттән тыш хәлләр булганда барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү системаларының әзерлек дәрәҗәсе;

гражданнар оборонасының саклык корылмалары, индивидуаль саклану чаралары һәм индивидуаль саклануның медицина чаралары белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсе;

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт программасы аша гамәлгә ашырыла торган чаралар, стратегик өстенлектән – кеше капиталын формалаштырудан һәм туплаудан чыгып, Стратегия-2030 максатларына ирешүгә этәргеч бирә.

Икътисад тармакларында һәм дәүләт идарәсе өлкәсендә
дәүләт идарәсе бурычлары, аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Гражданнар оборонасын үстерү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә төп бурычлар түбәндәгеләр:

янгыннар куркынычын социаль кабул ителә торган дәрәҗәгә кадәр киметү (янгыннар чыгу аркасында һәлак булучылар һәм җәрәхәт алучылар санын киметүне кертеп);

Татарстан Республикасы халкын, территорияләрен һәм инфраструктура объектларын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклауны арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен азайту, гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасының су объектларында халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген арттыру;

иҗтимагый иминлекнең, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге иминлегенең гомуми дәрәҗәсен арттыру (янарга мөмкин булган куркынычларны фаразлау, мониторинглау, кисәтү һәм бетерү, гадәттән тыш хәлләр һәм хокук бозулар салган зыяннарны бетерүне контрольдә тоту);

гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы белән идарә итү органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында мониторинглый, фаразлый һәм карарлар кабул итүдә ярдәм итә торган аппарат-программа комплексларын һәм техник чараларны үстерү;

бердәм интеграция платформасы базасында халыкка гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында үзәктән хәбәр итүнең төбәк автоматлаштырылган системасын үстерү һәм модернизацияләү;

хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар аркасында фаразлана һәм килеп чыга торган куркынычларны, шулай ук гадәттән тыш хәлләр, янгыннар һәм су объектларында һәлакәтләр килеп чыгу рискларын исәпкә алып, гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы идарәсе, көчләре һәм чаралары органнары составын һәм структурасын камилләштерү;

гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча хәрби конфликтлар булганда яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук гадәттән тыш хәлләр, янгыннар һәм су объектларында һәлакәтләр булганда килеп чыга торган куркынычлардан халыкның сакланылу дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү ысулларын, чараларын һәм алымнарын камилләштерү;

Татарстан Республикасының төбәк үсеше өстенлекләрен исәпкә алып, Янгыннан каршы дәүләт хезмәтенең һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм формированиеләре, янгыннан коткару бүлекчәләренең нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

янгыннан коткару бүлекчәләренең хәрби коткару формированиеләрен, һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен җиһазландыру өчен билгеләнгән техник чараларны камилләштерү;

гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын үз билгеләнеше буенча файдаланырга әзер булуны тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү, аларны заманча җиһаз һәм махсус техника белән җиһазландыру;

гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны гадәттән тыш хәлләрдә эш итү гамәлләренә әзерләү;

гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү;

риск юнәлешендәге алымны куллануга нигезләнгән янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыруның үзгәрүчән механизмнарын һәм заманча технологияләрен кулланышка кертү һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен тәэмин итү;

янгын сүндерү бүлекчәләре биналарын һәм бүлмәләрен һәм гражданнар оборонасы складларын төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә иҗтимагый берләшмәләрне һәм башка социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итү.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклауның нәтиҗәле координацияләнгән системасын булдырырга, янгын куркынычсызлыгының югары дәрәҗәсен тәэмин итәргә, янгыннар һәм аларда һәлак булучылар санын киметергә, суда кешеләрнең иминлеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Тәкъдим ителә торган чаралардан өстәмә уңай социаль нәтиҗә төбәктә эш урыннары санын арттырырга, шулай ук хезмәт шартларын яхшыртырга (янгын сүндерү техникасының һәм һәлакәттән коткару җайланмасының яңа үрнәкләрен кертү, бүлекчәләрне кирәкле әйберләр һәм махсус мөлкәт белән комплектлау исәбенә механикалаштыруны һәм хезмәт куркынычсызлыгын арттырырга) мөмкинлек бирәчәк.

Гадәттән тыш хәлләр, янгыннар, аварияләр һәм һәлакәтләр рискларын киметү өлкәсендә идарә итүне координацияләү механизмнарын үстерүгә, гадәттән тыш хәлләрдә ашыгыч ярдәм күрсәтү системаларын оптимальләштерүгә, гражданнарның тормыш иминлеге культурасын булдыруга юнәлдерелгән программа чараларын гамәлгә ашыруның ахыргы нәтиҗәсе – Татарстан Республикасы гражданнарының гомерен һәм сәламәтлеген саклау, гадәттән тыш хәлләр, янгыннар һәм су объектларындагы һәлакәтләр аркасында Татарстан Республикасы икътисадына китерә торган зыяннарны киметү, экосистемаларның төрлелеген саклау, экология һәм ресурс потенциалын арттыру.

---